**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 декабрендәге 5253 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Киров районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 715 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:50:000000:6463;
- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Киров районы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 2 ел;

1.2. гариза бирүче: «ТатДорТрансИнвест» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләүнең нигезләре: гариза бирүченең гаризасы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Гариза бирүчегә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәүне тәкъдим итәргә;

5. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр

басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 декабрендәге
5253 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Киров районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб: 1:1000
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | Урамнар (гамәлдәге) |
| | Кызыл сызыклар (расланган) |

| | |
|---|---|
| | Ясала торган җир кишәрлекләренең чикләре (проект.) |
| | Җир кишәрлекләре |
| | Кадастр кварталлары |
| | Капиталь төзелеш (линия) объектлары |
| | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| 16:50:000000 | кадастр кварталы |
| 16:50:000000:6463 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр |